**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе сәбәпле **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет төзү турында» 2013 елның 30 гыйнварындагы ПУ-71 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1098 номерлы, 2016 елның 7 маендагы ПУ-405 номерлы, 2017 елның 17 апрелендәге ПУ-310 номерлы, 2018 елның 13 апрелендәге ПУ-308 номерлы, 2018 елның 6 июлендәге ПУ-473 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы һәм 2020 елның 17 апрелендәге ПУ-236 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан Р.Т. Борһановны, Н.М. Владимировны, Т.В. Забегинаны, Р.З. Закировны чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Скирда Максим Владимировичны – Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;

Шакиров Данис Фәнис улын – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисен (килешү буенча);

Яковлев Константин Геннадиевичны – Татарстан халыклары ассамблеясе Советы Башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан халыклары ассамблеясе Советы рәисе урынбасарын (килешү буенча);

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Г.Ф. Габдрахманованың – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты этнологик тикшеренүләр бүлеге мөдире (килешү буенча)»;

С.К. Жаксыбаевның – «Татарстан Республикасының «Казахстан» казах милли-мәдәни мохтарияте Советы рәисе (килешү буенча)»;

В.Н. Любченконың – «Татарстан Республикасының берләштерелгән төбәк украин милли-мәдәни мохтарияте идарәсе рәисе (килешү буенча)»;

К.И. Сәмигуллинның – «Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие (килешү буенча)»;

Г.Ә. Хәсәновның – «Татарстан Республикасы башкорт милли-мәдәни мохтарияте – Татарстан Республикасы башкортлары корылтае (конгрессы) рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2020 ел, 05 ноябрь
№ ПУ-727